ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ Лениногорск КАРАР

22.05.2019 №198

«Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча шәһәр җирлеге вәкаләтләрен муниципаль район дәрәҗәсенә тапшыру турында» 2018 елның 17 маендагы 152 номерлы Лениногорск шәһәр Советы карары белән расланган Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге дәрәҗәсенә тапшыру турында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Килешүгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 47нче статьясы 2нче часте нигезендә, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча шәһәр җирлеге вәкаләтләрен муниципаль район дәрәҗәсенә тапшыру турында» 2018 елның 17 маендагы 152 номерлы Лениногорск шәһәр Советы карары белән расланган Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге дәрәҗәсенә тапшыру турында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Килешүгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 нчы бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге Килешү рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә һәм 31.12.2018 елга кадәр гамәлдә була».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Килешү үтәлешен контрольдә тотуны икътисад, салымнар, финанслар һәм эшмәкәрлекне үстерү буенча даими комиссия рәисе Р.Ә. Шәмсетдиновка йөкләргә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов